**КАРАР**
**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Уразлы авыл җирлеге Кече Карамалы авылында гражданнарга үзара салым кертү турында**

**09 нчы декабрь 2024 ел** **№ 5**

“Россия Федерациясендә җирле узидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 121-ФЗ номерлы Федераль законнын 25,1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле узидарә турында” 2004 елнын 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кече Карамал авылында гражданнар җыены **карар итте** :

1. 2025 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Уразлы авыл җирлеге территориясе, Кече Карамалы авылында яшәү урыны буенча теркәлгән, ташламалы категорияләрдән тыш (беренче төркем инвалидлар,көндезге формада укучы студентлар,мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзалары), Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Уразлы авыл җирлеге территориясендә яшәүче, җирлек территориясендә тавыш бирергә хокукы булган, яшәү урыны буенча турыдан-туры теркәлгән, һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәгеләрне үтәү буенча юнәлтергә:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү;

-ремонт, коймалар урнаштыру, традицион җирләү урыннарын төзекләндерү.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Кече Карамалы авылы, Кече урамы,1 нче йорт, авыл клубы бинасы; шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә урнаштырырга.

Халык җыенында рәислек итүче ,
Татарстан Республикасы Кама
Тамагы муниципаль районы

Уразлы  авыл җирлеге башлыгы:                                        М.Г.Хәмидуллин